ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«22» декабрь 2020 ел** **№ 1051**

**Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 20 декабрендәге 1139 номерлы «Арча муниципаль районы коммуналь комплексы оешмаларының 2020 елга халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләренә тарифлар турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Арча районы прокуратурасының 2020 елның 30 декабрендәге 02-08-02/127-2020 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 20 декабрендәге 1139 номерлы карарына протесты нигезендә, Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга нигезләнеп, Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Арча муниципаль районы коммуналь комплексы оешмаларының 2020 елга халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләренә тарифлар турында» 2019 елның 20 декабрендәге 1139 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.
- 3 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http://arsk.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Фазыловка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Мөхәррәмов

*Арча муниципаль районы*
*башкарма комитетының*
*22.12.* 2020 ел, №*1051*
*карарына 2 нче кушымта*

**Муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучыларга торак урыныннан файдаланган өчен (наемга алган өчен)**
**БАЗА СТАВКАСЫ**

| Түләү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге | 2020 елга хезмәт күрсәтү өчен үлчәү берәмлегенең база ставкасы (сум) |
|---|---|---|
| Наем буенча база ставкасы | Аена торак урынның гомуми мәйданы кв. м. | Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2019елның 20 декабрендәге 1140 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре һәм социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннардан файдаланучылар өчен түләү (наем өчен түләү) күләмен исәпләү методикасы нигезендә. |